ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**04.09.2019** **Чистай шәһәре** **№ 453**

“2015-2021 елларга Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районында
коррупциягә каршы сәясәтне
гамәлгә ашыру” муниципаль программасына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Чистай муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү, коррупцион хокук бозуларны кисәтүгә ярдәм итүче чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында һәм “2015-2021 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” дәүләт программасын раслау турындагы 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакындагы 17.06.2009 елдагы 495 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына нигезләнеп, Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының “2015-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” муниципаль программасы турында”гы 2014 елның 20 ноябрендәге 736 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта “2015-2021” санын “2015-2022” санына алмаштырырга»;

Әлеге карар белән расланган, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында «2015-2020 елларга коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру (алга таба – Программа):

исемендә “2015-2021” санын “2015-2022” санына алмаштырырга»;

программаның паспортында:

“Программаның исеме” өлешендә “2015-2021” саннарын “2015-2022” саннарына алмаштырырга”;

“Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары” өлешендә “2015-2021” саннарын “2015-2022” саннары белән алмаштырырга”;

III Бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2015-2022 елларда районның җирле бюджеты акчалары исәбеннән Программаны финанслауның гомуми күләме - 360 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: (сум)

| Ел | ТР Чистай муниципаль районының җирле бюджеты акчалары |
|---|---|
| 2015 | 42,0 |
| 2016 | 42,0 |
| 2017 | 42,0 |
| 2018 | 42,0 |
| 2019 | 48,0 |
| 2020 | 48,0 |
| 2021 | 48,0 |
| 2022 | 48,0 |

Программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм Чистай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Моннан тыш, Программаны тормышка ашыру чараларын башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаларны файдалану күздә тотыла»;

программаның IV бүлегендәге бишенче абзацында “2021 елга” сүзләрен “2022 елга кадәр” сүзләренә алмаштырырга”;

программаның кушымтасында “2015-2021” санын “2015-2022” саны белән алмаштырырга”.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты карар проектына карата**

**КИЛЕШТЕРҮ КӘГАЗЕ**

**1. Документның атамасы** “2015-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”

**2.Проект әзерләнде** Ефимов А. Т. Чистай муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе.

**3. Җитәкче** ____________________________________________

__________________________ **« 4 » сентябрь 2019ел**

(имза)

**Проектны тапшыру вакыты:** **« 4 » сентябрь 2019ел**

**4. Бүлек һәм хезмәт җитәкчеләренең визалары:**

| Килештерүче бүлекчәнең исеме, вазыйфасы | Ф.И.О. | Килештерү буенча тапшыру датасы | Имза, килештерү датасы, искәрмәләрнең кыскача эчтәлеге | Искәрмә төзәтелгән, имза, датасы |
|---|---|---|---|---|
| ЧМР Башкарма комитеты эшләре идарәчесе | О.В.Заглядова | | | |
| ЧМР Советы җирлекләрнең ММИ белән хезмәттәшлек итү бүлеге башлыгы | И.Ш.Садриева | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

**5. Эшләп бетерү өчен тапшырылды**

____________________________________________

(датасы, кемнән)

**6. Имзага тапшырылды**

____________________________________________

(датасы, гомуми бүлек визасы)